КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 июнь г.Казань № 466

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 423250, Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ленин проспекты, 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ) 2018 елның 1 сентябреннән бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

бу карарны кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә:

«Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ бетерү комиссиясе составын расларга;

«Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ бетерү тәртибен һәм вакытларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

«Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ бетерү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУнең бетерелү процессында булуы турындагы мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен теркәүче органга тапшырырга;

бу карарны кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә тонган 30 көн эчендә бетерелә торган оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәттән, алга таба файдалану турында Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тәкъдимнәр кертергә;

учреждение бетерелү аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә, шулай ук «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУсен бетерү буенча законнарда күздә тотылган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ йөкләмәләре, шул исәптән суд карарларын үтәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы булып, «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ функцияләрен һәм гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тәкъдим иткән исемлек нигезендә «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУнә элек беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен законнарда билгеләнгән тәртиптә ике ай  эчендә бирүне тәэмин итәргә.

5. «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Алый парус» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ бетерү чараларын үткәргәннән соң бушаган акча Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмаган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә халыкка социаль хезмәт күрсәтү тармагында социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарын компенсацияләүгә (кайтаруга) субсидияләр рәвешендә гарантлар бирүгә юнәлтелә.

6. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына бу карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук аларны бетергәндә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законына тиешле

үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

7. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икъътттисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә бу карарның 2 нче һәм 4 нче пунктларында күрсәтелгән барлык чараларны төгәлләгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин